УКАЗ
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
УКАЗЫ

Татарстан Республикасының В.Е. Алемасов исемендәге дәүләт премиясен гамәлгә кую турында

Яшь галимнәренең инженерлык фәннәре өлкәсендә фәнни, фәнни-техник һәм инновация эшчәнлеген стимуллаштыру һәм Россия фәннәр академиясе академигы, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең шәрәфле әгъзасы, 2 тапкыр СССР Дәүләт премиясе лауреаты В.Е. Алемасовның исемен мәңгеләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасының В.Е. Алемасов исемендәге дәүләт премиясен гамәлгә куярга.

2. Татарстан Республикасының В.Е. Алемасов исемендәге дәүләт премиясе турындагы нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).

3. Татарстан Республикасының В.Е. Алемасов исемендәге дәүләт премиясен бирү комитетын оештырырга, аның турындагы нигезләмәне (2 нче кушымта) һәм аның составын (3 нче кушымта) расларга.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны финанслауга Татарстан Республикасы бюджетыннан, 2015 елдан башлап, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенә акча бүлүне тәэмин итәргә.

5. Татарстан Республикасы Президентының «Фән һәм техника, мәгариф, мәдәният, әдәбият һәм сәнгать, массакүләм мәгълүмат чаралары өлкәсендә күренекле казанышларга ирешкән өчен, салым түләүчеләр тарафыннан алына торган, салым салынырга тиеш булмаган суммалы бүләкләр исемлеген раслау турында» 2007 елның 3 декабрендәге ПУ-651 номерлы Указы белән расланган Фән һәм техника, мәгариф, мәдәният, әдәбият һәм сәнгать, массакүләм мәгълүмат чаралары өлкәсендә күренекле казанышларга ирешкән өчен, салым түләүчеләр тарафыннан алына торган, салым салынырга тиеш булмаган суммалы бүләкләр исемлегенә түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

«5. Татарстан Республикасының В.Е. Алемасов исемендәге дәүләт премиясе.».

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2014 ел, 22 сентябрь
№ ПУ-913

Татарстан Республикасы
Президентының
2014 елның « 22 » сентябрендәге
ПУ- 913 номерлы Указына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасының В.Е. Алемасов исемендәге дәүләт премиясе турында нигезләмә

1. Татарстан Республикасының В.Е. Алемасов исемендәге дәүләт премиясе (алга таба – В.Е. Алемасов исемендәге премия) яшь галимнәргә инженерлык фәннәре өлкәсендә күренекле фәнни казанышлары, фән һәм сәнәгатьнең өстенлекле тармаклары үсешенә зур өлеш кертүләре өчен бирелә.

2. В.Е. Алемасов исемендәге премия Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан Татарстан Республикасының В.Е. Алемасов исемендәге дәүләт премиясен бирү комитеты (алга таба – Комитет) тәкъдимнәренә нигезләнеп тапшырыла.

3. Ел саен 1 июльдә В.Е. Алемасов исемендәге һәрберсе 75 сум күләмендә өч бирелә.

4. В.Е. Алемасов исемендәге премияне алуга Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан фәнни оешмаларда, сәнәгать предприятиеләрендә яисә мәгариф оешмаларында (алга таба – Татарстан Республикасы оешмалары һәм предприятиеләре) фәнни тикшерүләр алып баручы 35 яше тулмаган затлар тәкъдим ителергә мөмкин. Яшь галимнәр коллективлары В.Е. Алемасов исемендәге премияне алуга тәкъдим ителә алмый.

5. В.Е. Алемасов исемендәге премияне алырга теләүчеләрне (алга таба – премия алырга теләүчеләр) тәкъдим итү документлары Татарстан Республикасы оешмалары һәм предприятиеләре тарафыннан ел саен 1 майга кадәр бирелә.

Премия алырга теләүчеләрнең эшләрен характерлаучы документлар исемлеге, аларны рәсмиләштерүгә таләпләр, аларны бирү тәртибе һәм эшләрне бәяләү критерийлары Комитет тарафыннан билгеләнә һәм Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

6. Комитет, премияне алырга теләүчеләрне күрсәтү өчен документлар кабул итү тәмамланганнан соң, аларны башлангыч карау эшен уздыра, аның йомгаклары буенча төзеләчәк эксперт комиссияләре санын, аларның фәнни юнәлешен, составын һәм эш тәртибен билгели һәм раслый.

Премияне алырга теләүчеләрне күрсәтү өчен документлар аларга фәнни бәяләмә бирү өчен тиешле фәнни юнәлештәге эксперт комиссияләренә тапшырыла.

7. Комитет, билгеләнгән тәртиптә, эксперт комиссияләре бәяләмәләре нигезендә Татарстан Республикасы Президентына В.Е. Алемасов исемендәге премияне тапшыруга кагылышлы тәкъдимнәр керту турында карар кабул итә

һәм 1 июньгә кадәр аларны Татарстан Республикасы Президенты каравына кертә.

8. В.Е. Алемасов исемендәге премиягә лаек булган затларга «В.Е. Алемасов исемендәге премия лауреаты» дигән исем бирелә һәм тантаналы шартларда акчалата бүләк, диплом, лауреатлык билгесе һәм аның таныклыгы тапшырыла.

9. В.Е. Алемасов исемендәге премия дипломнарын, лауреатлык билгеләрен һәм таныклыкларын эшләтеп алуны, шулай ук В.Е. Алемасов исемендәге премияне тапшыруны Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе оештыра.

Татарстан Республикасы
Президентының
2014 елның «_22_» сентябрендәге
ПУ-913_ номерлы Указына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасының В.Е. Алемасов исемендәге дәүләт премиясен бирү комитеты турында нигезләмә

1. Татарстан Республикасының В.Е. Алемасов исемендәге дәүләт премиясен бирү комитеты (алга таба – Комитет) Татарстан Республикасының В.Е. Алемасов исемендәге дәүләт премиясен (алга таба – В.Е. Алемасов исемендәге премия) бирү буенча чараларны әзерләү һәм уздыруны оештыру максатларында төзелде.

2. Комитет Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына һәм башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасының В.Е. Алемасов исемендәге дәүләт премиясе турында нигезләмәгә, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып эшчәнлек алып бара.

3. В.Е. Алемасов исемендәге премияне алырга теләүчеләр эшләрен карап тикшерүне оештыру, Татарстан Республикасы Президентына В.Е. Алемасов исемендәге премияне тапшыру турында тәкъдимнәр керту Комитетның төп бурычы булып тора.

4. Комитетның функцияләре:

В.Е. Алемасов исемендәге премияне алырга теләүчеләр эшләрен кабул итүне һәм карап тикшерүне оештыру;

эксперт комиссияләре эшен оештыру, аларның составын һәм эш тәртибен раслау;

эксперт комиссияләренең бәяләмәләрен тикшерү;

Татарстан Республикасы Президентына В.Е. Алемасов исемендәге премияне тапшыру турында тәкъдимнәр керту;

В.Е. Алемасов исемендәге премия дипломы, лауреат билгесе һәм аның таныклыгы тасвирламаларын һәм үрнәкләрен раслау.

5. Комитет түбәндәгеләргә хокуклы:

дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, шулай ук фәнни һәм башка оешмалардан, законнарда билгеләнгән тәртиптә, Комитет карамагындагы мәсьәләләр буенча материаллар һәм мәгълүмат соратырга;

Комитет компетенциясенә кергән мәсьәләләрне хәл итү өчен эксперт комиссияләре төзергә;

билгеләнгән тәртиптә Комитет эшчәнлегенә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, югары белем бирү мәгариф оешмалары, шулай ук фәнни һәм башка оешмалар вәкилләрен җәлеп итәргә.

6. Комитет вазыйфалары:

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан фәнни оешмалар, сәнәгать предприятиеләре һәм мәгариф оешмалары белән В.Е. Алемасов исемендәге премияне тапшыру мәсьәләләре буенча үзара эшчәнлекне оештыру;

эксперт комиссияләре эшен мәгълүмати һәм оештыру-техник тәэмин итү;

эксперт комиссияләренең В.Е. Алемасов исемендәге премияне бирү турындагы бәяләмәләрен үз вакытында карау һәм Татарстан Республикасы Президенты каравына премияне бирү турында тәкъдимнәр кертү.

7. Комитет составын Татарстан Республикасы Президенты раслый.

8. Комитет составына Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, җәмәгатьчелек, югары белем бирү мәгариф оешмалары, шулай ук Татарстан Республикасының фәнни һәм башка оешмалары вәкилләре керә.

Комитетның барлык әгъзалары үз эшчәнлеген түләүсез нигездә башкара.

9. Комитет утырышлары кирәк булган саен, ләкин елга кимендә ике тапкыр уздырыла һәм, әгәр дә аларда Комитет әгъзаларының яртысыннан күбрәге катнашса, гамәлгә хокуклы дип санала.

10. Комитет эшчәнлегенә – Комитет рәисе, ә ул булмаганда Комитет рәисе урынбасары җитәкчелек итә.

11. Комитет рәисе Комитет эшен планлаштыра, Комитет утырышларын билгели һәм алып бара.

12. Утырышта тавыш бирү хокукы булган Комитет секретаре Комитет әгъзалары арасыннан Комитет рәисе тарафыннан билгеләп куела.

13. Комитет секретаре Комитет утырышларын әзерләү һәм уздыру буенча оештыру эшләрен һәм техник эшләрне башкара, шул исәптән премияне алырга теләүчеләр эшләре турында Комитет каравына кертелгән документларны һәм мәгълүматларны тикшерә, шулай ук Комитет утырышлары беркетмәләрен алып бара.

14. Комитет карарлары яшерен яки ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавыш бирү ысулы Комитет карарлары белән билгеләнә. Комитет карарлары, утырышта катнашучы Комитет әгъзаларының яртысыннан күбрәге хуплап тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала. Тавышлар тигез булганда, Комитет рәисе тавышы хәлиткеч булып санала.

15. Комитет карары беркетмә белән рәсмиләштерелә, аңа Комитет секретаре имза куя һәм рәислек итүче аны раслый.

16. Комитет эшчәнлеген матди-техник һәм финанс ягыннан тәэмин итү Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе тарафыннан тормышка ашырыла.

Татарстан Республикасы
Президентының
2014 елның «22» сентябрендәге
ПУ-913 номерлы Указына
3 нче кушымта

Татарстан Республикасының В.Е. Алемасов исемендәге дәүләт премиясен бирү комитеты составы

Сәлахов Мәкъзүм Хәлимулла улы	Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты, Комитет рәисе
Гыйльметдинов Альберт Харис улы	А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшерену техник университеты – КАИ ректоры, Комитет рәисе урынбасары (килешү буенча)
Абдуллин Айрат Лестал улы	Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе вице-президенты
Бугаков Игорь Сергеевич	«Казан вертолет заводы» ачык акционер җәмгыяте генераль директорының фәнни-техник стратегия буенча урынбасары (килешү буенча)
Гортышов Юрий Федорович	А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшерену техник университеты – КАИ президенты (килешү буенча)
Гуреев Виктор Михайлович	А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшерену техник университеты – КАИ үсеш буенча проректоры (килешү буенча)
Драгунских Игорь Викторович	«Серго исемендәге завод» җитештерү берләшмәсе» ачык акционер җәмгыяте генераль директорының техник үсеш буенча урынбасары – баш инженеры (килешү буенча)

Зарипов Равил Хаммат улы	Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры
Карпов Александр Николаевич	«А.М. Горький исемендәге Зеленодольск заводы» ачык акционер җәмгыяте генераль директорының беренче урынбасары (килешү буенча)
Герасимов Юрий Иванович	«КАМАЗ» ачык акционер җәмгыяте генераль директорының беренче урынбасары – башкарма директор (килешү буенча)
Нургалиев Данис Карл улы	Казан (Идел буе) федераль университетының фәнни эш буенча проректоры (килешү буенча)
Солозобов Валерий Иванович	«Туполев» ачык акционер җәмгыяте генераль директорының проектлаштыру, фәнни-тикшерену эше һәм тәҗрибә-конструкторлык эше буенча урынбасары (килешү буенча)
Фәттахов Энгель Нәвап улы	Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры
Шәмсетдинов Эмиль Васил улы	Казан дәүләт энергетика университетының фәнни эш буенча проректоры (килешү буенча)